**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

17.06.2020 № 411

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 19 сентябрендәге 854 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 7 апрелендәге 456 номерлы «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2015 елның 25 мартындагы 272 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» карарына таянып, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 19 сентябрендәге 854 номерлы «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы мәгариф объектларының террорчылыктан саклануына карата таләпләрне һәм мәгариф объектларының (территорияләренең) куркынычсызлыгы паспортының формасын раслау турында» карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

38 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«38. Объектның (территориянең) иминлек паспортын килештерү әлеге таләпләрнең 37 пунктында күрсәтелгән территориаль органнарга (бүлекчәләргә) кергән көннән алып 10 эш көне эчендә гамәлгә ашырыла. Кисәтүләр булган очракта объектның (территориянең) иминлеге паспорты күрсәтелгән срокта объектка хокуклы кешегә эшләп бетерүгә кире кайтарыла.

Объектның (территориянең) иминлек паспортын өстәмә эшләп бетерү хокукка ия булучыга кайтарылган көннән алып 10 эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Объектның (территориянең) куркынычсызлык паспортын раслау объектка ия булучыга кайтарылган көннән 7 эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.»

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче Л.Н. Маняпов